**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8872**
**22.09.2023**

Яр Чаллы шәһәренең «Дельфин» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41, 53, 55 статьялары, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Дельфин» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Дельфин» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1442 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 22 сентябрендәге
8872 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Дельфин» олимпия резервы спорт мәктәбе»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Йөзү/синхрон йөзү буенча төркемнәрдә түләүле физкультура-сәламәтләндерү дәресләре | ай | 2500,00 |
| 2. | Йөзү/синхрон йөзү буенча ял көне төркемнәрендә түләүле физкультура-сәламәтләндерү дәресләре | ай | 850,00 |
| 3. | Йөзү-сәламәтләндерү буенча төркемдә шөгыльләнү | 45 мин. | 350,00 |
| 4. | Аквааэробика буенча төркемдә шөгыльләнү | 45 мин. | 350,00 |
| 5. | Йөзү буенча персональ дәрес | 45 минут | 550,00 |
| 6. | Бассейнда 45 минут булу (бер тапкыр, зурлар) Эш көннәрендә 17.00 сәгатькә кадәр, шимбә, якшәмбе | 45 минут | 200,00 |
| 7. | Бассейнда 45 минут булу (бер тапкыр, зурлар) Эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән соң | 45 минут | 250,00 |
| 8. | Бассейнда 45 минут булу (бер тапкыр, балалар) Эш көннәрендә 17.00 сәгатькә кадәр, шимбә, якшәмбе | 45 минут | 100,00 |
| 9. | Бассейнда 45 минут булу (бер тапкыр, балалар) Эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән соң | 45 минут | 150,00 |
| 10. | Бассейнда 45 минут булу (бер тапкыр, ташламалы) Эш көннәрендә 17.00 сәгатькә кадәр, шимбә, якшәмбе* | 45 минут | 100,00 |
| 11. | Бассейнда 45 минут булу (бер тапкыр, ташламалы) Эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән соң* | 45 минут | 150,00 |
| 12. | Бассейнда 45 минут булу (бер тапкыр, укучылар төркемнәре өчен – укытучы белән физкультура дәресләре) | 45 минут | 70,00 |
| 13. | Тернәкләндерү үзәге (сауна) | сәгать | 1000,00 |
| 14. | Тернәкләндерү үзәге (хамам) | сәгать | 1000,00 |
| 15. | Спорт корылмасы хезмәте (бассейн 1 юл) | 45 минут | 3000,00 |
| 16. | Спорт корылмалары хезмәте (корыда йөзү (хореография) залы) | 45 минут | 550,00 |
| 17. | Бассейнга йөрү өчен айлык абонемент | 1 кешегә | 3000,00 |
| 18. | Бассейнга йөрү өчен еллык абонемент | 1 кешегә | 21000,00 |
| 19. | Бассейнга йөрү өчен айлык абонемент (гражданнарның ташламалы категориясе)* | 1 кешегә | 1500,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20. | Бассейнга йөрү өчен еллык абонемент (гражданнарның ташламалы категориясе)* | 1 кешегә | 10500,00 |
| 21. | Йөзү-сәламәтләндерү буенча төркемдә шөгыльләнүгә айлык абонемент | ай | 3500,00 |
| 22. | Аквааэробика буенча төркемдә шөгыльләнүгә айлык абонемент | ай | 3500,00 |
| 23. | Солярий | 1 минут | 18,00 |
| 24. | Солярийга абонемент | 100 минут | 1300,00 |

* яшь буенча һәм тиешле еллар эшләгән пенсионерлар, күп балалы гаиләләрнең ата-аналары, 23 яшькә кадәрге көндезге уку формасында укучы студентлар, Россия Федерациясе территориясендә һәм башка дәүләтләр территориясендә хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм ветераннар, шулай ук Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнар, ятим балалар, II, III төркем инвалидлар, I төркем инвалидларны озатып йөрүчеләр (бер тапкыр бару).

5 яшькә кадәрге балалар, инвалид балалар, I төркем инвалидлар бушлай.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева